РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин ур., 15

Тел.:8(84364)2-63-02, факс:8(84364)2-63-04,e-mail:Kukmor.Kuk@tatar.ru,www:kukmor.tatarstan.ru


«Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проекты хакында фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында

# БӘЯЛӘМӘ

Рәсмиләштерү датасы: 22.06.2026

Гавами тыңлауларда Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара шәһәре, Мәҗит Гафури ур, 8а җир кишәрлеге адресында урнашкан кадастр номеры 16:23:260235:552 булган, 1 309 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәхси торак төзелеше (Ж1) зонасында «кибетләр» – рөхсәт бирү турында боерык проекты каралды.

Гавами тыңлауларда катнашучылар саны 11 кеше тәшкил итте.
Әлеге бәяләмә 2026 елның 19 июнендәге 5 номерлы гавами тыңлаулар беркетмәсе нигезендә әзерләнде.

Иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар) уздыру чорында аларда катнашучылардан тәкъдимнәр һәм кисәтүләр килде, алар буенча түбәндәге киңәшләр бирелде:

| т/б № | Тәкъдимнең һәм (яисә) искәрмәнең эчтәлеге | Тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алуның максатка ярашлылыгы яисә максатка ярашсызлыгы турында дәлилләнгән тәкъдимнәр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Территориядә даими яшәүче гражданнарның тәкъдимнәре һәм искәрмәләре | | |
| 1 | Фикер алышына торган җир кишәрлегенең бер өлеше кар һәм яңгыр сулары агып төшә торган урында урнашкан, җир кишәрлеген киртәләп алган очракта, су ага торган ермакка керү юлы ябылачак, бу якындагы торак йортларны су басу куркынычы тудыра. | Гавами тыңлауларда катнашучының кисәтүе игътибарга алынды, чөнки, Комиссия фикеренчә, ул нигезле. |
| 2 | Кибет өчен җир кишәрлеге якындагы торак йортларны су басу куркынычы булмаслык итеп урнаштырылырга тиеш. | Гавами тыңлауларда катнашучының кисәтүе игътибарга алынды, чөнки, Комиссия фикеренчә, ул нигезле. |
| Башка катнашучыларның тәкъдимнәре һәм искәрмәләре | | |
| | **кермәде** | |
| | | |

**Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча йомгак:**

1. Гавами тыңлауларны узган һәм ябык дип таныйрга.

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Кукмара шәһәре, Мәҗит Гафури ур., 8а җир кишәрлеге адресында урнашкан кадастр номеры 16:23:260235:552 булган, 1 309 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәхси торак төзелеше (Ж1) зонасында «кибетләр» – рөхсәт бирүне

тәкъдим итмәскә.
Әлеге Бәяләмәне Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru урнаштырырга

Комиссия рәисе _____________ Андреев В.Н.

Комиссиия әгъзалары:

_______________ Закиров И.Г.

________________ Мөбәрәкшин Р.И.

________________ Хәйруллин Р.Р.

________________ Гарәфетдинова Э.Р.

________________ Габдрахманова А.Н. [1]

[1] Иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар) беркетмәсенә җирле үзидарә органы җитәкчесе – иҗтимагый фикер алышуларны (гавами тыңлауларны) оештыручы яисә, әгәр иҗтимагый фикер алышуларны (гавами тыңлауларны) оештыручы күрсәтелгән орган булса, коллегиаль киңәшмә органының барлык әгъзалары имза сала.